| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕАКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР АКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Зур Аксу авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2022 ел № 24/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советы 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылуда катнашу турында " 2019 елның 15 ноябрьдәге 73/7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.13 пунктчасы белән тулыландырырга:
«3.13. нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирү.»;
түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктын өстәргә:
«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре күрсәтелгән 3 пунктта нотариаль гамәлләр башкарылган очракта нотариаль документларны саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм куллануны тәэмин итә. Җирлек бетерелгән яки муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, бетерелгән яки үзгәртелгән җирле үзидарә органының нотариаль документлары җирле үзидарә органына тапшырыла.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларына, Чүпрәле муниципаль районы рәсми сайтына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru).

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы урынбасары: С.Н.Никитин